БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 май 2020 ел № 249

**Балтач муниципаль районының депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үзенең, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып бирү артык зур булмаса, җаваплылык чараларын куллану Тәртибе хакындагы карар кабул итү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, «Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар, контракт буенча муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы, «Муниципаль вазыйфаларга, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан бирелгән белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары, Балтач муниципаль районының Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Балтач муниципаль районының депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үзенең, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып бирү артык зур булмаса, җаваплылык чараларын куллану Тәртибе хакындагы карарны кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Балтач муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге карарның 1 пункты белән расланган Тәртипнең үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе Э.Ф. Гариповага йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин